РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

НИЖНЕШИТЦИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422067, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Нижние Шитцы, ул. Тукая, 15
тел. (84362) 46-4-42

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШЫТСУ АВЫЛ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422067, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Түбән Шытсу авылы, Тукай урамы, 15
тел. (84362) 46-4-42

He-mail: shic.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

24.07.2024 № 22

Татарстан Республикасының Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының 01.03.2016 елда № 8 карары белән расланган, Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының вазыйфаи затлар тарафыннан гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 09.12.2023 елгы №124-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитеты карары белән расланган Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибенә 01.03.2016 елгы № 8 «Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл башкарма комитетының вазыйфаи затлары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм шәхсән кабул итү Тәртибен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 7 пунктның 7.2 пунктчасында «электрон адрес» сүзләрен «федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланганда электрон почта адресы йә шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) Бердәм порталы,» дигән сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 7 пунктның 7.3 пунктчасында «электрон почта адресы» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 14 пунктның 14.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркем инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II төркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.»

1.4. 18 пунктның 5 пунктчасын «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча яисә шәхси кабинет адресы буенча күрсәтелгән Бердәм порталда» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Түбән Шытсу авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shitsi адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Түбән Шытсу авыл
җирлеге башлыгы Б.М.Мәүлетов